ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09.12.2019 г. Заинск № 618

**"2020-2022 елларда Зәй муниципаль районында халык арасында наркотиклар куллануны кисәтү» муниципаль программасын раслау турында**

Зәй муниципаль районы территориясендә наркотикларның законсыз әйләнешенә каршы тору, наркотик һәм психотроп матдәләр куллану һәм тарату белән бәйле хокук бозуларны кисәтү максатыннан, "Наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау турында" 2009 елның 29 октябрендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән, Зәй муниципаль районы Уставына таянып, Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә**

1. "2020-2022 елларда Зәй муниципаль районында халык арасында наркотиклар куллануны кисәтү» муниципаль программасын кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карар басылып чыкканнан соң үз көченә керә.
3. Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А. В. Чапковка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Ф.Хафизов**

**ЭЧТӘЛЕК**

1. Паспорт
2. Программаның характеристикасы һәм аның чишелешен максатчан программ методлар белән нигезләү
3. Программаның төп максатлары һәм бурычлары
4. Программа чаралары системасы
5. Наркомания һәм наркотиклар белән бәйле җинаятьләрне кисәтүне методик яктан тәэмин итү
6. Наркомания һәм наркотиклар белән бәйле җинаятьләрне медицина профилактикасы чаралары
7. Наркотиклар белән бәйле җинаятьләрне кисәтү
8. Наркоманияне беренчел кисәтү чаралары
9. Программаны тормышка ашыру механизмы
10. Программаны тормышка ашыруның социаль-икътисади һәм башка нәтиҗәлелегенә бәя бирү
11. Программаның чаралар планы
12. Кабул ителгән кыскартулар

# "ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНДА 2020-2022 ЕЛЛАРДА ХАЛЫК АРАСЫНДА НАРКОТИКЛАР КУЛЛАНУНЫ КИСӘТҮ" ПРОГРАММАСЫ

## ПРОГРАММАНЫҢ ПАСПОРТЫ

<table>
<tr><td>Программаның исеме</td><td>"ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНДА 2020-2022 ЕЛЛАРДА ХАЛЫК АРАСЫНДА НАРКОТИКЛАР КУЛЛАНУНЫ КИСӘТҮ" ПРОГРАММАСЫ (алга таба - программа)</td></tr>
<tr><td>Программаның заказчы-координаторы</td><td>Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты</td></tr>
<tr><td>Программаны төп эшләүчеләр</td><td>"Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре буенча идарәсе" муниципаль казна учреждениесе</td></tr>
<tr><td>Программаның максатлары</td><td>Район территориясендә наркотикларның законсыз әйләнешенә каршы тору, наркотик һәм психотроп матдәләр куллану һәм тарату белән бәйле хокук бозуларны кисәтү.</td></tr>
<tr><td>Программаның бурычлары</td><td>-наркомания һәм наркотиклар белән бәйле җинаятьчелекне кисәтү эшен методик яктан тәэмин итү;<br>- наркотикларның законсыз әйләнеше һәм медицина булмаган куллану өлкәсендә җинаятьләрне һәм башка хокук бозуларны кисәтү;<br>- наркоманияне кисәтү һәм наркотикларга каршы пропаганда өлкәсендәге чараларны активлаштыру;<br>- профилактик эшнең нәтиҗәлелеген күтәрү.</td></tr>
<tr><td>Программаны гамәлгә ашыру сроклары</td><td>2020-2022 еллар</td></tr>
<tr><td>Финанслауның күләмнәре һәм чыганаклары</td><td>
<table>
<tr><td>Еллар</td><td>Зәй муниципаль районы бюджеты акчалары (мең сум)</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>500,00</td></tr>
<tr><td>2021</td><td>500,00</td></tr>
<tr><td>2022</td><td>500,00</td></tr>
<tr><td>Бар-лыгы</td><td>1500,00</td></tr>
</table>
<br>Муниципаль программа чараларын финанслау тиешле елга Зәй муниципаль районы бюджетында расланган ассигнованиеләр чикләрендә гамәлгә ашырыла. Муниципаль программаны тормышка</td></tr>
</table>

| | |
|---|---|
| | ашыруга тотылган акча күләме, район бюджеты мөмкинлекләреннән, инфляция процессларыннан һәм Зәй муниципаль районы территориясендәге икътисади вәзгыятьтән чыгып, аныкланырга һәм төзәтмәләр кертелергә мөмкин. |
| Программаны башкаручылар | - "Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре идарәсе" МКУ<br>- "Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе" МКУ<br>- "Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният идарәсе" МКУ;<br>- "Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының физик культура, спорт һәм туризм идарәсе" МКУ;<br>- Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча район хакимияте комиссиясе;<br>- "Зәй үзәк район хастаханәсе" дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе;<br>- "Татмедиа" АҖ филиалы - Зәй ТВ телерадиокомпаниясе<br>- Зәй муниципаль районының наркотикларга каршы көрәш комиссиясе;<br>- Россия Эчке эшләр министрлыгының Зәй районы буенча бүлеге (килешү буенча) |
| Наркотикларга каршы профилактика субъектлары эшчәнлеген координацияләү | Наркотиклар куллануны кисәтү субъектлары эшчәнлеген координацияләү Зәй муниципаль районы Башкарма комитетына йөкләнә. |

## 1. Программаның характеристикасы һәм аның чишелешен максатчан программалар белән нигезләү

"2020 - 2022 елларга Зәй муниципаль районында наркотикларны явыз ният белән куллануга һәм аларның законсыз әйләнешенә каршы торуның комплексы чаралары" максатчан программасы (алга таба - программа) Россия Федерациясе Конституциясе, "Наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр турында" 1998 елның 8 гыйнварындагы 3-ФЗ номерлы Федераль закон (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән), «Наркомания һәм токсикоманияне профилактикалау турында» 2009 елның 29 октябрендәге 50 номерлы Татарстан Республикасы Законы, «2014-2020 елларга Татарстан Республикасында җинаятьчелеккә каршы

көрәш җәмәгать тәртибен тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 16 октябрендәге 764 номерлы карары нигезендә эшләнде.

Наркотик һәм криминоген вәзгыятьтә уңай үзгәрешләргә ирешүгә юнәлтелгән бурычларны хәл итү җитди ярдәмнән, хакимият һәм идарә органнарының, дәүләтнеке булмаган структураларның, иҗтимагый берләшмәләрнең һәм гражданнарның тырышлыгын берләштерүдән башка мөмкин түгел. Бу әлеге мәсьәләне җайга салуга программалы-максатчан якын килү кирәклеген аңлата.

## 2. Программаның төп максатлары һәм бурычлары

Программаның төп максаты - Зәй муниципаль районында һөнәри грамоталы кисәтү эшен активлаштыру аша наркомания һәм наркотиклар белән бәйле җинаятьчелек таралуны минималь куркыныч дәрәҗәгә кадәр киметү, наркоманиянең чимал базасына каршы көрәш чараларын көчәйтү.

Программа 2020-2022 елларга исәпләнгән һәм түбәндәге бурычларны хәл итүне күздә тота:

- наркомания һәм наркотиклар белән бәйле җинаятьләрне кисәтү эшен методик яктан тәэмин итү;
- наркотикларның законсыз әйләнеше һәм медицина булмаган куллану өлкәсендә җинаятьләрне һәм башка хокук бозуларны кисәтү;
- наркоманияне кисәтү һәм наркотикларга каршы пропаганда өлкәсендәге чараларны активлаштыру;
- кисәтү эшенең нәтиҗәлелеген күтәрү.

## 3. Программа чаралары системасы

Программа район территориясендә наркотиклар куллануны һәм наркотикларның законсыз әйләнешен кисәтү өлкәсендә төп юнәлешләр буенча чараларны үз эченә ала:

- наркомания һәм наркотиклар белән бәйле җинаятьләрне кисәтүне методик яктан тәэмин итү;
- наркомания һәм наркотиклар белән бәйле җинаятьләрне медицина профилактикасы чаралары;
- наркотиклар белән бәйле җинаятьләрне кисәтү;
- наркоманияне беренчел кисәтү чаралары.

### 3.1 Наркомания һәм наркотиклар белән бәйле җинаятьләрне методик яктан профилактикалауны методик яктан тәэмин итү

Әлеге юнәлешне тормышка ашыру барышында түбәндәгеләр планлаштырыла:

- наркомания һәм наркотиклар белән бәйле җинаятьләрне кисәтү мәсьәләләре буенча семинарлар һәм конференцияләр үткәрү;

- наркотикларның законсыз әйләнешенә бәйле затларның интеграцияләнгән банкларын булдыр.

### 3.2 Наркомания һәм наркотиклар белән бәйле җинаятьләрне медицина кисәтүе чаралары

Әлеге пунктны тормышка ашыру буенча көчләр наркотикларның законсыз әйләнешенә һәм наркотиклар куллану белән бәйле хокук бозуларны кисәтү субъектларының техник җиһазландырылуын яхшыртуга юнәлдереләчәк.

### 3.3 Наркотиклар белән бәйле җинаятьләрне кисәтү

Әлеге юнәлешне тормышка ашырып, түбәндәге чаралар үткәрү планлаштырыла:

- әлеге проблемага кагылышлы семинарлар һәм конференцияләр үткәрү ;

- массакүләм спорт чаралары оештыру;

- шушы проблема буенча күрсәтмә һәм методик агитация материаллары бастырып чыгару һәм сатып алу.

### 3.4 Наркоманияне беренчел кисәтү чаралары

Әлеге юнәлешкә килгәндә, наркоманияне профилактикалау субъектларын техник яктан җиһазландыруны яхшырту, шулай ук наркотикларга бәйле балигъ булмаганнарны, ачыкланган очракта, дәвалау юлы белән тормышка ашырылачак.

Программа 3 елга, 2020-2022 еллар чорына исәпләнгән, ул җирле бюджет хисабына тормышка ашырыла. Әлеге программада каралган чараларны гамәлгә ашыру өчен программада катнашучы көчләрне берләштерү зарур.

## 4. Программаны тормышка ашыру механизмы

Программа үтәлешенә гомуми контроль ведомствоара район наркотикларга каршы көрәш комиссиясе тарафыннан гамәлгә ашырыла, аның функцияләренә программа чаралары күрсәткечләрен, программаны тормышка ашыру механизмын һәм башкаручылар составын аныклау керә.

Программаның үтәлешен контрольдә тоту Зәй муниципаль районы Башкарма комитетына йөкләнә .

Ел саен, хисап чорыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр программада катнашучылар Зәй муниципаль районы Башкарма комитетына аның үтәлеше турында мәгълүмат бирәләр.

Программа чараларының үтәлеше һәм нәтиҗәләре ведомствоара район

наркотикларга каршы көрәш комиссиясе утырышында карала.

## 5. Программаны тормышка ашыруның социаль-икътисади һәм башка нәтиҗәлелегенә бәя бирү

Программаны тормышка ашыру барышында планлаштырыла:

- хокук саклау органнары, медицина хезмәтләре, авыл советлары, иҗтимагый оешмалар, мәгариф учреждениеләренең һәм халыкның район территориясендә наркотикларның законсыз әйләнешенә һәм куллануга каршы көрәштә көчләрен берләштерү.

Программаның гамәлгә ашырыла торган юнәлешләре нәтиҗәдә наркотиклар таралуны булдырмаска һәм Зәй муниципаль районында хокук тәртибе торышын тотрыклыландыруга ярдәм итәчәк.

# 6. ПРОГРАММАНЫҢ ЧАРАЛАР ПЛАНЫ

| № п/п | Чараның исеме | Максатчан чаралар, елларга бүлеп | | | Нәтиҗәлелек күрсәткече | Чараларны башкаручылар |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2020 | 2021 | 2022 | | |
| I. Наркомания һәм наркоҗинаятьне профилактикалауны методик яктан тәэмин итү | | | | | | |
| 1.1 | Наркоситуация һәм наркотиклар куллануга ярдәм итүче сәбәпләргә мониторинг үткәрү | - | - | - | НЗӘ(наркотиклар-ның законсыз әйләнеше) белән бәйле җинаятьләрне киметү | Полиции бүлеге |
| 1.2 | Наркотиклар куллануга каршы видеоролик эшләү һәм сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау | 20,0 | 20,0 | 20,0 | НЗӘ белән бәйле җинаятьләрне киметү | Яшьләр эшләре идарәсе |
| 1.3 | Наркомания һәм наркоҗинаятьне профилактикалау буенча тапшырулар циклын эшләү | 80,0 | 80,0 | 80,0 | НЗӘ белән бәйле җинаятьләрне киметү | ЯЭИ,, Телерадиокомпания ЗайТВ |
| 1.5 | "Наркотикларсыз тормыш!» темасыны рәсемнәр бәйгесе | - | - | - | НЗӘ белән бәйле җинаятьләрне киметү | МИ, КИ, ЯЭИ, ФКСТ МКУ |
| 1.6 | Мәгълүмат баннеры эшләү һәм урнаштыру | 26,0 | 26,0 | 26,0 | яшүсмерләрнең хокукый грамоталылыгын арттыру | Яшләр эшләре идарәсе |
| 1.7 | Профилактик чаралар үткәрү өчен методик кулланмалар әзерләү һәм тәҗрибәне гомумиләштерү | - | - | - | НЗӘ белән бәйле җинаятьләрне киметү | МИ, КИ, ЯЭИ, ФКСТ МКУ КДН, ЭЭБ |
| 1.8 | Наркотикларның законсыз әйләнешенә бәйле затларның, шулай ук наркотикларга бәйле гаиләләрдәге яшүсмерләрнең интеграцияләнгән банкларын булдыру | - | - | | НЗӘ белән бәйле җинаятьләрне киметү | Полиция бүлеге, КДН |
| II. Наркомания һәм наркоҗинаятьне медицина профилактикасы чаралары | | | | | | |
| 2.1 | Наркотик кулланучы затларны ачыклау, аларны диагностикалау һәм дәвалау чараларын үткәрү буенча эш. | - | - | - | НЗӘ белән бәйле җинаятьләрне киметү | Зәй ҮРХ |
| III. Наркоҗинаятьләрне кисәтү | | | | | | |
| 3.1 | Медицина булмаган куллану фактларын ачыклау буенча эш һәм гражданнарның | - | - | - | НЗӘ белән бәйле җинаятьләрне киметү | КДН, ЭЭБ |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | массакүләм ял итү урыннарында яшьләр арасында наркотикларның законсыз әйләнеше | | | | | |
| 3.2 | Массакүләм мәгълүмат чараларында һәм урам рекламасы чараларында «кайнар линия» телефоннары һәм ышаныч телефоннары эшен пропагандалау | - | - | - | НЗӘ белән бәйле җинаятьләрне киметү | ЭЭБ |
| 3.3 | Наркотиклы үсемлекләрнең законсыз чәчүлекләрен һәм кыргый үсүче чыганакларны ачыклау буенча чаралар оештыру | - | - | - | НЗӘ белән бәйле җинаятьләрне киметү | ЭЭБ |
| 3.4 | Даруханә һәм сәламәтлек саклау учреждениеләрендә наркотик, психотроп һәм көчле тәэсир итүче матдәләрне сатуны системалы тикшерүне тәэмин итү | - | - | - | НЗӘ белән бәйле җинаятьләрне киметү | ЗәйҮРХ(килешү буенча), ЭЭБ |
| IV. Наркоманияне беренчел кисәтү чаралары | | | | | | |
| 4.1 | Наркоманиягә каршы көрәш көннәрендә 1 март, 26 июнь көнне яшьләр арасында наркотикларга каршы массакүләм акцияләр (митинглар, урам йөрешләре, концертлар)үткәрү | - | - | - | яшүсмерләрнең Хокукый грамоталылыгын арттыру | МИ, КИ, ЯЭИ, ФКСТ МКУ |
| 4.2 | Балигъ булмаганнар арасында наркотик куллануны кисәтү максатыннан түгәрәк өстәлләр, тематик чаралар, акцияләр оештыру һәм үткәрү (Тәмәке тартудан баш тарту көне, Халыкара наркотиклар әйләнешенә каршы көрәш көне, Бөтендөнья сәламәтлек көне һ. б.) | 5,0 | 5,0 | 5,0 | яшүсмерләрнең хокукый грамоталылыгын арттыру | МИ, КИ, ЯЭИ |
| 4.3 | "Спорт-наркотикларга каршы" шигаре астында спорт чаралары үткәрү | - | - | - | НЗӘ белән бәйле җинаятьләрне киметү | ФКСТ МКУ |
| 4.4 | Наркотикларга каршы айлык кысаларында чаралар | 20,0 | 20,0 | 20,0 | НЗӘ белән бәйле җинаятьләрне киметү | МИ, ЯЭИ, ФКСТ МКУ |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 45 | Районда социаль - тискәре күренешләрне, хокук бозуларны, наркотиклар белән көрәш һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру атналыгы кысаларында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе, эчке эшләр бүлегендә исәптә торучы балалар белән чаралар үткәрү | 10,0 | 10,0 | 10,0 | НЗӘ белән бәйле җинаятьләрне киметү | МИ, КИ, ЯЭИ, ФКСТ МКУ |
| 4.6 | Яшүсмерләрнең ялын оештыру, аларны иҗади берләшмәләргә, спорт секцияләренә, үзешчән сәнгатькә җәлеп итү. | - | - | - | НЗӘ белән бәйле җинаятьләрне киметү | МИ, КИ, ЯЭИ, ФКСТ МКУ |
| 4.7 | Наркотик характердагы кыргый үсемлекләр үстерү урыннарын ачыклау максатыннан " Мәк» операциясен үткәрү | - | - | - | НЗӘ белән бәйле җинаятьләрне киметү | ЭЭБ |
| 4.8 | Җәйге мәктәп яны лагерьлары программаларына профилактик чаралар кертү | - | - | - | яшүсмерләрнең хокукый грамоталылыгын арттыру | Мәгариф идарәсе |
| 4.9 | Район халкына консультатив ярдәм күрсәтү | - | - | - | НЗӘ белән бәйле җинаятьләрне киметү | Зәй муниципаль районының наркотикларга каршы көрәш комиссиясе |
| 4.13 | Наркотикларга каршы тематика буенча агарту эшен оештыру | - | - | - | яшүсмерләрнең хокукый грамоталылыгын арттыру | Зәй муниципаль районының наркотикларга каршы көрәш комиссиясе |
| 4.14 | Китапханә фондларыннан тематик әдәбият күргәзмәләре оештыру | - | - | - | яшүсмерләрнең хокукый грамоталылыгын арттыру | Мәдәният идарәсе |
| 4.15 | "Тәмәке тартуны ничек ташларга»," Сәламәт яшәү рәвеше, бу нәрсә…» шушы темаларга класс сәгате һәм әңгәмәләр үткәрү | - | - | - | яшүсмерләрнең хокукый грамоталылыгын арттыру | Мәгариф идарәсе |
| 4.16 | Ата-аналар һәм балалар өчен сәламәт яшәү рәвеше нигезләре буенча | - | - | | яшүсмерләрнең хокукый грамоталылыгын арттыру | Мәгариф идарәсе |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | очрашулар оештыру | | | | | |
| 4.17 | Сәламәтлек көненә багышланган акцияләрдә катнашу | - | - | - | НЗӘ белән бәйле җинаятьләрне кимету | МИ, КИ, ЯЭИ, ФКСТ МКУ |
| 4.18 | Халыкның төрле төркемнәре арасында наркотикларга каршы иҗади һәм спорт-сәламәтләндерү конкурслары уздыру:<br>- "Автоледи»;<br>- «Карлы ял тукталышы» божралы узышлары;<br>- «Спортның офис төрләре буенча чемпионат»;<br>- «Победный» велоузышы-авыл һәм эшләүче яшьләрнең туристлык слеты;<br>- "Мәктәп КВН лигасы" шәһәр уеннар»;<br>- эшләүче яшьләр арасында "КВН лигасы" шәһәр уеннары;<br>- «Һөнәре буенча иң яхшы" һөнәри осталык бәйгесе | 339,00 | 339,00 | 339,00 | НЗӘ белән бәйле җинаятьләрне кимету | Яшьләр эшләре идарәсе |
| | **БАРЛЫГЫ:** | **500,00** | **500,00** | **500,00** | | |

## 7. Кабул ителгән кыскартулар

БК – Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы башкарма комитеты.

ЭЭБ – Россия Эчке эшләр министрлыгының Зәй районы буенча бүлеге.

ЯЭИ МКУ – "Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре буенча идарәсе» муниципаль казна учреждениесе.

ФКСТИ МКУ – «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының Физик культура, спорт һәм туризм идарәсе» муниципаль казна учреждениесе.

МИ МКУ УО – “Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе.

«Зәй ҮРХ» ДАССУ - «Зәй үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе.

КИ МКУ - "Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният идарәсе» муниципаль казна учреждениесе.

КДН – Зәй муниципаль районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиясе

НЗӘ - наркотикларның законсыз әйләнеше .